*... ялт иттер күңелеңне ак нур белән!*

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга
2015 ел. ДЕКАБРЬ

## Тайгак юлдан атламыйк!!!

Махсус чыгарылыш

### *Наркомания, эчүчелек кебек яман күренешләрнең үлем юлы икәнен без ничек аңлыйбыз?*

*Без яшәгән дәвер, авызларда хәмер,*
*Ризыгыбыз харам, сүзләребез ялган.*
*Аңлый алмый бәндә үзен һаман, һаман.*
*Тәгәри ул түбән, җәһәннәмгә табан...*
*Әсир итә аны ләззәте һәм тәме,*
*Комагай һәм явыз аның һәр гамәле.*
*Марихуан, әфьюн, гашиш, анаша...*
*Бер генә куллана, гомергә ябыша...*
*Ничә кат кабатлый, бусы дип соңгысы,*
*Туктаталмый аны җанының иңрәве.*
*Күзеннән нур качкан, юк аның иманы*
*Куркыныч, караңгы, кояшсыз һәр таңы.*
*Заманмы бутала, бәндәме ялгыша,*
*Гел шулай барса – киләчәк бик яман.*
*Аңлый алмый бәндә шуны һаман, һаман*
*Ризыгыбыз харам, сүзләрдә - гел ялган...*

*Г. Гөлназ.*



“Уйланыгыз!!!” Сафиуллин Булат рәсеме. 13 яшь.

**Тәмәке тарту, эчүчелек, наркомания кешелекнең тамырына балта чаба. Кешелек әкрен әкрен генә упкынга атлый. Тәмәке төтене, алкоголь, ялган ләззәт томанына адашкан кешеләр, гүзәл җир йөзенә бәхет һәм шатлык чыганагы булып туларын онытып, газап һәм кайгы китереп, Җир ананың йөрәген сызлатып, үзләре дә кибеп, сызланып, әрнеп китеп баралар... Наркомания, эчүчелек тимер богау кебек кешелекне бугазлап килә. Әкрен генә, әмма бик ышанычлы эре адымнар белән торган саен зуррак биләмәләргә хуҗа була бара, комсыз ланып берсеннән-берсе гүзәл тормышларны йота бара... Без аңа каршы тора алырбызмы?**

# Син беләсеңме?

Нәрсә соң ул наркотик? Наркотик грекчадан оету, сиземләүне бетерү дигән сүз. Наркотик матдәләр кабул иткән кеше берникадәр вакыт эчендә барлык уңай сыйфатларын югалта: аны уку да, эш тә кызыксындырмый. Аңа әтисе дә, әнисе дә, туганнары да кирәк түгел. Аның өчен мәхәббәт тә, дуслык та юк. Аның бөтен уе, бөтен тормыш максаты – кайдан да булса акча табып, наркотик сатып алырга. Героин, анаша, LSD, экстази... Алар арасында табигать анабыз дәва итеп кенә яратканнары да, синтетик юл белән уйлап табылганнары да бар. Соңгылары бигрәк тә куркыныч. Чөнки алар турыдан-туры баш миенең эшчәнлегенә тәэсир итәләр һәм бер тапкыр кулланганнан соң ук үзләренә бәйле ясыйлар. Бер тапкыр андый наркотикның тәмен тәмләүче инде кабат аның кулларыннан ычкына алмый. Әгәр наркоман алдагы порция наркотикны алмаса, “ломка синдромы” башлана. Һәм бик еш кына ул үлем белән бетә.

**Наркотиклар берьюлы өч буынны юк итә. Гадәттә наркомания чоңгылына баткан кереп баткан яшьләрнең гомер озынлыгы, гадәттә, 4-5 елдан артмый. Исән чакта ук алар гепатит, ВИЧ, һәм башка куркыныч авырулар йоктыра. Нәтиҗәдә нәселләрен дәвам итәргә бала-чагалары да калмый. Наркоманнарның ата-аналары балаларының тайгак юлга кереп китүләрен, ачы язмышларын авыр кичерә. Алар өчен бу зур кайгы, хурлык, оят. Чиксез хәсрәттән аларның да гомерләре вакытсыз өзелә.**

Наркоманияне җиңәргә мөмкинме? Галимнәр әле тиз генә булмас диләр. Һәрхәлдә алар бүгенге хәлне белеп әйтә. Җәмгыятебез үзе ялганга корылган, ришвәтчелек, коррупция өстенлек итә, коточкыч тамыр җәйгән наркомафия зур байлыкка ия. Әлбәттә, мондый шартларда наркоманияне җиңүгә ышаныч бик аз. Ләкин һәркем аек акыл белән наркотикларның ни икәнен аңлап , сәламәт яшәү рәвешен сайласа – киләчәгебезне өметле дия алабыз.

Рания 16 яшь

## Өзелде яшь гомер.

***Мәңге кайтмаска дип,***
***Үзем теләп киттем.***
***Татлы иде ләззәт...***
***Тик ул булды кыйммәт.***
***Киләчәкне түгел,***
***Сине сайлап алдым,***
***Комсыз ак үлемгә***
***Үзем теләп бардым.***
***Калтыранган кулдан***
***Энәм төшеп китте.***
***Шул агулы елан***
***Башларыма җитте.***
***Доза арты доза...***
***Иң яманы шулдыр.***
***“Кайдан акча табыйм?”***
***Башта тик шул уйдыр.***
***Меңәрләгән энә***
***Кадалган башыма,***
***Ак үлем җәтмәсен***
***Корган каршыма.***
***Кан юлына –***
***Тормыш тамырыма***
***Керде әрсез энә.***
***Соңгы тамчы, соңгы сулыш,***
***Ямь-яшь гомер сүнә.***
***Соңлап килгән көздә***
***Кырау суккан гөлдәй***
***Сүнә ямь-яшь гомер.***
***Кызганыч...***
***Тик әле ул соңгысы түгел...***

***Гөл кызы . 14 яшь***



“САЙЛА!” Газимзянова Рания рәсеме. 16 яшь

**Мин ни өчен наркотик кулланмыйм?**
***(анкетадан юллар)***

- Минем тормышым берәү генә, аны берничә елдан авыр газаплар белән төгәллисем килми.
- Көн саен наркотикларга акча түгеп, якыннарымны газапка саласым килми.
- Урлашкан өчен төрмәгә яки махсус диспансерга эләгергә теләмим.
- Наркотикларга да, аларны таратучыларга да бәйле булырга теләмим.
- СПИД белән авырудан куркам.
- Минем балаларымның балаларын да сәламәт килеш, шат итеп күрәсем килә.
- Файдалы эш белән шөгыльләнеп акча эшлисем килә.

## *Гасыр афәте.*

*Наркомания һәм алкоголизм. Бу ике чир янәшә тора. Алкоголизм тормышыбызга күп бәхетсезлекләр китерә, ни кадәр асыл кешеләрне әрәм итә. Алкоголь чыннан да акылдан яздыручы наркотик ул. Аның тәэсирендә кан тамырлары стеналарының эластиклыгы бик нык кими, шунлыктан баш миенә кислород һәм туклыклы матдәләр килү тоткарлана. Нәтиҗәдә күзәнәкләр күпләп сафтан чыга. Мәсәлән, 100 грамм сыра - 3000, 100 грамм шәраб – 5000, ә 100 грамм аракы 7500 ләп шундый күзәнәкне юк итә. Даими рәвештә аракы эчкән кеше 5-7 ел эчендә хроник алкоголикка әйләнергә мөмкин. Ә яшьләрдә исә бу процессс ике тапкыр тизрәк бара.*

*Еш кына авыл уртасында урнашкан кибет янынан узарга туры килә. Кайсы вакытта гына булмасын – кибет каршында сәләмә киемле, таушалган, ямьсез йөзле кешеләр була. Юк, алар ят кешеләр түгел мин аларның барысын да диярлек таныйм, әнә берсе минем таныш кызымның әтисе. Алар һәркөнне вакытларын шунда уздыралар. Аларга йорт та, бала да, эш тә кирәкми. Аларның инде нормаль халәткә кайтып яши алулары да мөмкин түгел, аракы парлары аларның миләрен киптергән. Ә йортта әти-әниләре, сабыйлары, хатыннары...*

*Эчүчелек татар авыллары өчен ят күренеш булган. Мәчетеннән яңгыраган азан тавышы халыкны намазга өндәгән. Фанилыкны куып талчыккан тәннәрен намаз белән ял иттергән халкым. Дөньяның бусын да, тегесен дә онытып 100 грамм эзләп йөрмәгән.*

*Бүген эчүчелек авылда тамыр җәйгәннән җәя бара. Эчүгә бирелеп өйләнә алмый калган егетләр, күрәләтә тормышларын исерек белән бәйләргә теләмичә ялгызы гына кртаючы кызлар, исерек ирдән тәмам туйган бәхетсез хатыннар, исерек әти оятыннан башларын иеп йөрүче балалар... Авылның йөзе шундыйга әйләнеп бара. Тагы да аянычы – аракыны инде хатын-кызларның да эчә башлавы. Исерек ир-атка күз күнгән иде инде - ә хатын-кызны исерек итеп күрү башка сыймый. Аның бит гаилә учагын яндырасы, балаларын тәрбиялисе бар.*

*Аракы үзенең ятьмәләренә яңадан-яңа корбаннар аулый бара. Авыл мәдәният йортына рәхәтләнеп күңел ачам дип чыгу юк – бирелә сүгенү, акыру, исереклек. Яшьләр, хәтта бик яшьләр үзләреннән чак кына кечкенә пиво шешәләре күтәреп “имеп” йөриләр. Үзләрен шул рәвешле текә кызлар, текә егетләр итеп күрсәтеп, әкрен генә алкашлыкка таба үз адымнарын ясый бирәләр.*

*Без упкын алдында. Ничек котылырга? Бәлки асылыбызга кайтып, дөнья мәшәкатьләреннән талган, арыган җаныбызга һәм тәнебезгә ялган бәхет, ял биргәнче аны бабайларыбыз кебек иман белән нығытыргадыр? Бәлки тарихи кыйбласызлык китергән гасыр афәте – алкоголизмнан нәкъ шулай гына алабыздыр?*

*Әгәр миндә шундый көч булса, мин бу җиһаннан аракы затын бер дә калдырмас идем. Аракы түктергән күз яшьләрен бергә җыя алсак, мөгаен диңгез кадәр булыр иде...*

*Г. Фәнил 14 яшь.*



***Минем тормышта чын наркоман күргәнем юк. Аның каравы алкашларны күргәнем бар. Аларның авыру йөзләрен, мәгънәсез сүзләрен мин бер дә яратмыйм. Минем уемча алар үз тормышларын үзләре җимерүчеләр. Минем алар кебек буласым килми. Наркоман да буласым килми. Сау-сәламәт килеш, туганнарыма, әти-әниемә кайгы китермичә, аларның горурлыгы булып яшисем килә. Сеңелләремә һәм киләчәктә очраячак тормыш иптәшемә ныклы терәк буласым килә.***

***Минем өчен оялуларын теләмим аларның.***

***М. Рифат 15 яшь***



## *Кулыңны бир миңа!*

Ялгыш кына авыз иттең дә син,
Котыла алмыйсың инде кабат.
Ялган бәхет уты бар дөньяңны
Алды бер мизгелдә кинәт ялмап.
Онытылды имеш кайгыларың.
Күңел газапларың чигенде.
Һәм нурланды дөнья, гүя сиңа
Кемдер алсу күзлек кигезде.
Үз бәхетен таба алмаганнар
Алданалар ялган ләззәткә.
Ә ул сине ычкындырмый кабат,
Әкрен генә сөйри ләхеткә.
Һәлакәткә таба сөйрәләсең,
Тик бер тамчы ләззәт теләнеп;
Тән хурланган, мал сатылган инде
Тик бер жаның калган терәлеп.
Тукта! Уйлан! Әле бит соң түгел!
Аер син ялганны чынныннан!!!
Тәүбә ит, арала жаныңны
Мәңгелек җәһәннәм утыннан.
Тәүбә ит, калдырма нәселеңә,
Әрнүле, каргышлы яманат.
Аңга кил, кулыңны бир миңа,
Алдыңда зур упкын, һәлакәт...

З. Миләүшә. 14 яшь.

## *Ломка*

Кая китте рәхәт, ләззәтләрем,
Бар дөньямны чолгап ут алды.
Янам, көям, шашам, саташам,
Көнем белән төнем буталды!
Әллә инде утлы җәһәннәмнең
Бер өлеше миңа күчкәнме?
Янам, янам... Күз яшем дә яна,
Тамырымдагы кан да пешкәнме?
Яна жаным, яна бөтен жирем.
Яна дөнья – барысын ут алган;
Яна аңның соңгы кисәкләре,
Йөрәгем дә әллә тукталган?
Ник торасыз читтә? Коткарыгыз!
Аралагыз мине газаптан!
Кайда әти-әни туганнарым?
Сез түгелме мине яраткан?..
Яна-яна акрын гына үләм,
Бер эзсез дөньядан мин китәм.
Табыгыз, бирегез бер тамчы!
Бер тамчы, аз гына, бер доза...
Югыйсә үләм бит, мин үләм.
Юк инде, кирәкми, артык соң.
Вакытында туталып булмады.
Мин үземчә яшәп гомеремә
Үзем куям соңгы ноктаны....
P.S. Моны мин язмадым, бары тик
Күңелемнән генә мин уйладым.
Күрергә язмасын беркемгә,
Раббымнан тик шуны сорыймын.

Г. Алинә. 15 яшь

**“…Дөньяга тәүге тапкыр авз салган кызчыкның әнисе алкаш һәм наркоман булган икән. гөнаһсыз сабый бала. Үкси-үкси, сулышына буыла-буыла елый. Ачыгу, һава житмәүдән түгел, нәни организм наркотик сорый, карында чакта бала шуңа ияләшкән. Нарасый тынып калды. Ломканы кичерә алмады. Керфек тә чыкмаган күз кабаклары мәңгелеккә ябылдылар…” Бу юллар үзәк матбугаттан. Уйлан! Син балаңа шундый язмыш телисеңме? Синең сайлау мөмкинлегең бар әле…**



“Язмышың үз кулыңда!” Г. Гөлинә 9 нчы сыйныф

“Минем сәламәт буласым килә, матур булып, бәхетле булып яшисем килә. Уңышлы карьера ясап, бөтенесе өчен горурлык буласым килә.”